# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында" 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4; 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 6; 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 4; 2009, № 1; 2011, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның дүртенче, алтынчы һәм җиденче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ статья өстәргә:
"$6^1$ статья. **Нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге**

Нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан тиешенчә Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.";

3) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2003 елның 24 июнендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 пунктының бишенче, җиденче һәм сигезенче абзацларын, 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 6);

2) "Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2005 елның 16 декабрендәге 128-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 20 июле
№ 61-ТРЗ